ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский,
422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печища авылы,
422592

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында

№1 12.04.2024

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында" Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнары җыенының 25.11.2023 ел, №4 карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 127 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан 79 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- гражданнар җыенында катнашкан 79 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;
- «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде
- 0 катнашучы тавыш бирүдән тыелып калды

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында халык җыенын булып узды, халык җыены нәтиҗәләре-чын дип танырга.
2. "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре турында" Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнары җыенының 25.11.2023 ел, №4 карарына үзгәрешләр кертү турында карарны танырга: «Сез 2024 елда Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылында Югары Ослан

муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегенең Ключищи авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (поселок эчендәге юлларны чокырлы ремонтлау)
- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су күтәрү манарасын урнаштыру).

3. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Ключищи авылы гражданнары җыенының нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Ш. Р. Азизов